РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ КУКМОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

20 ноябрь, 2020 ел Кукмара ш. № 30

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Территориаль планлаштыру схемасына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 9, 20, 21 статьялары нигезендә, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының территориаль планлаштыру схемасына үзгәрешләр кертү проектына Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 21 августындагы 10-53/10462 номерлы бәяләмәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Советы **карар бирде:**

1. Кукмара муниципаль районы Советының 2012 елның 19 декабрендәге 171 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Территориаль планлаштыру схемасына муниципаль районның электр белән тәэмин итү картасы белән территориаль планлаштыру схемасын нигезләү буенча материалларны эшләү һәм өстәү өлешендә үзгәрешләр кертергә.

2. Кукмара муниципаль районы Башкарма комитетына әлеге карарны Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга һәм расланган документны Россия Федерациясенең территориаль планлаштыру Федераль дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Кукмара муниципаль районы Советының шәһәр төзелеше һәм торак-коммуналь хуҗалык, табигый ресурслар һәм җирдән файдалану буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Район Башлыгы С.Д. Димитриев